БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» 10 2022 ел № 305

Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары турында

Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, "Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында" 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указына туры китереп, "Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында" 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзаларына түбәндәге ярдәм чараларын күрсәтергә:

1.1. 2022 елның 1 ноябреннән башлап мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында баланы карау һәм карап-тәрбияләп тору өчен алына торган түләүдән азат итү;

1.2. 2022 елның 1 октябреннән башлап муниципаль мәгариф оешмаларының 1-11 сыйныф укучыларын ике тапкыр бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов